ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2024 с.Старое Дрожжаное № 287

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы (21.06.2019 N 505, от 31.01.2020 N 54, от 26.07.2021 N 645, от 30.10.2021 N 1030, от 09.02.2022 N 102, от 01.04.2022 N 304, от 20.06.2022 N 587, от 14.09.2022 N 1002, от 21.02.2023 N 171, от 16.10.2023 N 1312, от 18.06.2024 № 434 карар редакциясендә) карарының гамәлдә булуын 2024 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларына гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән хезмәт шартларының үзгәрүе турында хәбәр итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартларына үзгәрешләр кертү турында» 27.01.2023 № 34 Татарстан

Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Р. Измайлов